Татарстан Республикасы Президенты Указы

**Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү документларын карау һәм бирү тәртибе турында» 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-828 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 23 июлендәге ПУ-494 номерлы, 2009 елның 27 февралендәге ПУ-106 номерлы һәм 2010 елның 22 июнендәге ПУ-397 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасындагы «һәм бүләкләүгә документлар бирү» дигән сүзләрне «бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта:

«кушымта итеп бирелүче тәртип турындагы Нигезләмә» сүзләрен «кушымта итеп бирелүче Тәртип» сүзләренә алмаштырырга;

«һәм бүләкләүгә документлар бирү» дигән сүзләрне «бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктның беренче һәм дүртенче абзацларында «медале» сүзләреннән алда «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

г) 2 пунктның өченче абзацында «һәр балага» сүзләрен «алтынчы һәм аннан соңгы һәр балага, бүләкләү көненә аларга өч яшь тулган булса» сүзләренә алмаштырырга;

д) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бүләкләнүче үлгән очракта, әгәр исән чагында аңа акчалата бүләк бирелмәгән булса, акчалата бүләк Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мирас итеп тапшырыла.»;

е) Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләүгә документларны карау һәм бирү тәртибе турында Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын, аңа таныклык формасын (үрнәген) һәм бүләкләү кәгазе формасын раслау турында» 2010 елның 22 июлендәге ПУ-397 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләүгә бүләкләү кәгазе формасын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге Указ үз көченә кергәнгә кадәр Татарстан Республикасы Президентына бүләкләүгә кертелгән алты һәм аннан күбрәк бала тәрбияләгән аналарга акчалата бүләкләү күләме алтынчы һәм аннан соңгы һәр балага, әгәр дә бүләкләү көненә алар бер яшькә җиткән булса, тиешенчә исәпләп, биш мең сумга арттырыла, дип билгеләргә.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2011 ел, 27 декабрь
№ ПУ-876